Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Урта Ушма поселогында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

17 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23.1нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Урта Ушма торак пунктында гражданнар җыены үткәрелеп карар итте:

1. 2025 елда Балтач районы Кече Лызи авыл җирлегенең Урта Ушма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булганнарга 500 сум күләмендә үзара салым кертергэ, үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән: 1нче һәм 2нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, сәләтсез гражданнардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, өлкән яшьтәге ялгыз пенсионерлардан, үз – үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче тулы булмаган куп балалы гаилә әгъзаларыннан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә ашыгыч яки контракт хезмәте узучы, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урта Ушма поселогының Лесная урамындагы юлны норматив норматив хәлгә китерү).

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А. С.Исмагилов